ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.04.2026 г. Заинск № 132

**Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 11 июлендәге 333 номерлы «2026-2030 елларга Зәй муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь шартлар белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары һәм "Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь шартлар белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары белән, «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык шартлары белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2026-2030 елларга «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2026-2030 елларга Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 11 июлендәге 333 номерлы карары белән расланган «2026-2030 елларга «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында яшь

гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасының 1 нче кушымтасына 35 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:
«Сатып алына торган торак бина (шул исәптән өлешле төзелеш объекты булып торучы) яисә торак йорт төзелеше Татарстан Республикасы территориясендә булырга тиеш».

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р. Н. Камаловага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Романов Р.А.
Тел.8(8555) 9-90-93